Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Новопольского сельского поселения**

Свободы ул, 39 п.Новопольский,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru
narvek@yandex.ru

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты**
Иреклек ур., 39 Новополька п,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru
narvek@yandex.ru

**КАРАР**

2019 елның 23 апреле №45

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерлык хезмәтен оештыру һәм аңа түләү шартлары турында

Бухгалтерлык хезмәтләре эшчәннәре хезмәтенә түләүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерлык хезмәтен оештыру һәм аңа түләү шартлары турында нигезләмәне расларга..
2. Әлеге карар нигезендә билгеләнүче эш хакы күләме, хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары күләме сакланганда һәм алар шул ук квалификация эшләрен башкарганда, аларга 2019 елның 31 мартына кадәр түләнгән хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.
3. Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге Советы 2018 елның 28 апрелендәге 177 номерлы карары гамәлен бу карарда күрсәтелгән Новополька авыл җирлеге эшчәннәре хезмәте өчен түләүгә җәелдермәскә.
4. Әлеге карар имза куелган мизгелдән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Новополька авыл җирлеге башкарма комитетына хезмәткәрләр вазыйфаларының атамаларын әлеге карарда каралганга туры китерүне тәэмин итәргә.
6. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодол муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үземдә калдырам.

Новополька авыл
җирлеге башлыгы Н.Ю.Якупов

Новополька авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның 23 апрелендәге
45 номерлы карарына кушымта

**Положение**
**об организации и условиях оплаты труда работников бухгалтерских служб Исполнительного комитета Новопольского сельского поселения Зеленодольского муниципального района ( за исключением должностей, отнесенных к должностям муниципальных служащих)**

1. Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерлык хезмәтләре эшчәннәре хезмәтен оештыру һәм аңа түләү шартлары турында әлеге нигезләмә бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм эшчәннәрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.
2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, аңа эшләгән еллары өчен айлык өстәмәдән, эшнең интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләүдән, эш нәтиҗәләре өчен премияләрдән тора.
3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектәге халык саны | Вазыйфа атамасы, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш бухгалтер | |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 15700 | |
| 3,5 меңнән күбрәк кеше | 17000 | |
| 1,9 меңнән күбрәк кеше | | 14500 |

Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасы кертү шарты булып муниципаль берәмлектә 1.9 меңнән күбрәк кеше саны тора.

4. Бухгалтерларга билгеләнә:
1) вазыйфаи окладка эшләгән еллары өчен айлык өстәмә түбәндәге күләмнәрдә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1дән 5 елга кадәр | 5 |
| 5тән 10 елга кадәр | 7 |
| 10 нан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладка эшнең интенсивлыгы өчен айлык өстәмә вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә;
3) еллык түләүле ял бирелгәндә бер тапкыр түләү еллык вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә;
Әгәр дә бухгалтерларга календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләү аңа эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә декабрьдә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән соңга калмыйча түләнә.
Еллык түләүле ял бирелгәндә бухгалтерларга бер тапкыр түләү беренче елында

календарь елда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елның 31 декаберенә кадәр санала.
4) акчалата бүләкләү, матди ярдәм билгеләнгән эш хакы фонды чикләрендә;
5) эш нәтиҗәләре буенча премия билгеләнгән эш хакы фонды чикләрендә (премия күләме бухгалтер эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләмендә чикләнми).

5. Бухгалтерларның эш хакы еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t)$$

монда:

$FOT$ – бухгалтерларның эш хакы еллык фонды;
$O_d$ – бухгалтерларга айга вазыйфаи оклад түләүгә акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$– эшләгән еллары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәгә, эшнең интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәгә, акчалата бүләкләүгә, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләүгә, матди ярдәмгә түләү акча суммасы;

n – бухгалтерларның штат саны;

k – 12 ай;

t – хезмәткә түләү буенча түләүне санау.